РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«14» ноябрь, 2025 Олы Кайбыч ав. № 23

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2023 елның 04 сентябрендәге 213 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2025 елның 03 октябрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2023 елның 04 сентябрендәге 213 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгәтүбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типлаштырылган квалификация таләпләре билгеләнә:

һөнәри белем дәрәҗәсенә карата:

вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен югары белем булу;

вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу.

муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгы — А.И. Рәхмәтуллин